ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 01 2023 г. № 40

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларына экспертиза, бәйсез экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 6 һәм 6.2 өлешләре нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларына экспертиза, бәйсез экспертиза үткәрү тәртибен раслапга (кушымта).

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның « 23 » гыйнвардагы
40 номерлы карары белән расланган
кушымта

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларына экспертиза, бәйсез экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан эшләнгән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларына экспертиза, бәйсез экспертиза үткәрү үзенчәлекләрен билгели (алга таба – Тәртип).

1.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларына экспертиза, бәйсез экспертиза предметы булып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларының аларга карата «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен бәяләү тора.

2. Административ регламентлар проектларына экспертиза, бәйсез экспертиза үткәрү тәртибе

2.1. Экспертиза үткәрү өчен, структур бүлекчә, административ регламент проектын эшләүче башка ведомство карамагындагы оешмалар (алга таба – проектны эшләүче) Түбән Кама муниципаль районы Советының хокук бүлегенә җибәрә:

а) административ регламент проекты белән бергә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау яки административ регламентка үзгәрешләр кертү, административ регламентны гамәлдән чыгару турында карар проекты;

б) карар проектына килештерү бите;

в) аңа барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән (булганда) үзгәрешләр кертелә торган яисә үз көчен югалткан дип танылган муниципаль хезмәт күрсәтүнең гамәлдәге административ регламенты күчермәсе;

г) административ регламент кабул итү мәсьәләсе буенча министрлыклар, ведомстволар һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр хатлары (булганда).

Хокук бүлеге административ регламент проектын (алга таба – проект) Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бәйсез экспертиза үткәрү өчен урнаштыруны гамәлгә ашыра, гражданнардан һәм оешмалардан тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итүне, аларны проектны эшләүче белән берлектә карауны тәэмин итә.

Бәйсез экспертиза үткәрү Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында административ регламент урнаштырылган көннән башлап 5 календарь көн тәшкил итә.

2.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары проектларына бәйсез экспертизаның тәкъдим ителгән мәсьәләләре исемлегенә аерым административ процедураларны һәм тулаем административ регламентны бәяләү керә, шул исәптән түбәндәге өлешендә:

административ процедураларның оптимальлеге, шул исәптән административ процедураларның һәм административ гамәлләрнең үтәү вакытын киметүне дә кертеп;

артык административ гамәлләрне бетерү;

гражданнарга һәм оешмаларга административ процедуралар һәм административ гамәлләр турында мәгълүмат бирү ысулларының оптималь булуы;

муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарының җайлылыгы һәм уңайлыгы таләпләрен үтәү, көтү урыннарының, мәгълүмат алу урыннарының һәм кирәкле документларны тутыру урыннарының кирәкле җиһазларын да кертеп.

административ регламентны рәсмиләштерүнең тулылыгын һәм дөреслеген бәяләү.

2.3. Хокук бүлеге, бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр алганнан соң, аларны проектны эшләүчегә карау өчен җибәрә.

Проектны эшләүче тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне карауны тәэмин итә, кирәк булганда проектка кирәкле үзгәрешләр кертә һәм кызыксынган гражданнарның һәм оешмаларның кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен исәпкә алу турында белешмә әзерли.

2.4. Административ регламентлар проектларына экспертиза һәм бәйсез экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча, хокук бүлеге тәкъдим ителгән карар проектын килештерә яки инициаторга сәбәпләрен күрсәтеп кире кайтара.